| СОВЕТ САЛИХОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САЛИХ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.12.2024. с.Новые Чути № 128

2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына

Салих авыл җирлеге бюджеты турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексына, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Салих авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Салих авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәгә таянып, Салих авыл җирлеге Советы КАРАРЫ:

1 Статья

1. 2025 елга Салих авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Салих авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 10 010,9 мең сум күләмендә;

2) Салих авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләмен 10 010,9 мең сум итеп;

3) Салих авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0 мең сум күләмендә.

2. 2026 елга һәм 2027 елга Салих авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Салих авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 2026 елга 10 214,4 мең сум һәм 2027 елга 10 396,9 мең сум күләмендә;

2) Салих авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 2026 елга 10 214,4 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 250,4 мең сум һәм 2027 елга 10 396,9 мең сум, шул исәптән шартлы рәвештә расланган чыгымнар 509,5 мең сум;

3) Салих авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 2026 елга 0 мең сум һәм 2027 елга 0 мең сум күләмендә.

3. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Салих авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарга 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2 Статья

1. 2026 елның 1 гыйнварына Салих авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән Салих авыл җирлеге бюджетының муниципаль эчке бурычының югары чиген муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә расларга.

2. 2027 елның 1 гыйнварына Салих авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән Салих авыл җирлеге бюджетының муниципаль эчке бурычының югары чиген муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә расларга.

3. 2028 елның 1 гыйнварына Салих авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча муниципаль эчке бурычның югары чиген 0 мең сум күләмендә, шул исәптән Салих авыл җирлеге бюджетының муниципаль эчке бурычының югары чиген муниципаль гарантияләр буенча 0 мең сум күләмендә расларга.

3 Статья

Салих авыл җирлеге бюджетында 2025 елга һәм 2026 һәм 2027 еллар план чорына фаразлана торган керемнәр күләмен әлеге карарга 2 нче кушымта нигезендә исәпкә алырга.

4 Статья

1. 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Салих авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын әлеге карарга 3 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Бюджет ассигнованиеләрен 2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Салих авыл җирлеге бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре төркемнәре буенча бүлүне әлеге карарга 4 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Норматив йөкләмәләрне үтәүгә Салих авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен 2025 елга 0 мең сум, 2026 елга 0 мең сум, 2027 елга 0 мең сум күләмендә расларга.

5 Статья

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруга җирлек бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертлар күләмен 2025 елга 5 117,7 мең сум күләмендә, 2026 елга җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итүгә шартлар тудыру чараларын тәэмин итүгә төзелгән килешүләр нигезендә расларга.5 117,7 мең сум күләмендә, 2027 елга 5 117,7 мең сум күләмендә.

2. Баулы муниципаль районы бюджетына әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертлар ай саен тигез өлешләрдә күчерелә дип билгеләргә.

6 Статья

1. Салих авыл җирлеге бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына күчерелергә тиешле бюджетара субсидияләр күләмен Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 44.10 статьясы нигезендә 2025 елга 35,9 мең сум, 2026 елга 25,9 мең сум, 2027 елга 24,6 мең сум итеп расларга.

2. Татарстан Республикасы бюджетына әлеге статьяда каралган бюджетара субсидияләрне күчерү ай саен тигез өлешләрдә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

7 Статья

Салих авыл җирлеге бюджетында бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә Баулы муниципаль районы бюджетыннан алына торган дотацияләрне 2025 елда 8 307,4 мең сум, 2026 елда 8 489,8 мең сум, 2027 елда 8 661,1 мең сум итеп исәпкә алырга.

8 Статья

Салих авыл җирлеге бюджетында җирлекләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыруга җирлекләр бюджетларына 2025 елда 183,0 мең сум, 2026 елда 200,1 мең сум, 2027 елда 207,3 мең сум субвенцияләрне исәпкә алырга.

9 Статья

Салих авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына 2025 елда муниципаль хезмәткәрләр һәм муниципаль казна учреждениеләре хезмәткәрләре санын арттыруга китерә торган карарлар кабул итмәскә киңәш итәргә.

10 Статья

Салих авыл җирлеге бюджетының 2025 елның 1 гыйнварына 2024 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле товарлар китерүгә, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Салих авыл җирлеге башкарма комитеты исеменнән төзелгән муниципаль контрактлар өчен түләүгә файдаланылмый калган бюджет ассигнованиеләре суммасыннан артмаган күләмдә калган акчалары, 2025 елда Салих авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.

11 Статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Баулы районы Казначылык Департаментының территориаль бүлеге төзелгән килешүләр нигезендә Салих авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне башкара.

12 Статья

Әлеге карарны мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә һәм Салих авыл җирлегенең «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтына урнаштырырга.

13 Статья

Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Салих авыл җирлеге башлыгы И. Н. Хәйруллин